**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** Казан ш. **БОЕРЫК**

__02.12.2021__ __1357-п__

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан Кече Чирмешән елгасы, Казансу елгасы, Кәминкә елгасы су объектларының су саклау зоналарын һәм яр буе саклык полосаларын билгеләү турында

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә (чыганактан 73,12 – 73,93 км аралыктагы кишәрлектә) Кече Чирмешән елгасының, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә (чыганактан 109,75 – 113,23 км аралыктагы кишәрлектә) Казансу елгасының, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә (чыганактан 6,97 – 9,02 км аралыктагы кишәрлектә) Кәминкә елгасының яр буе линиясенең бер өлеше урнашкан урынны (су объекты чикләрен) тәгаенләштерү эшләре уздырылуына бәйле рәвештә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 10 гыйнварындагы 17 номерлы карары белән расланган Су объектларының су саклау зоналары чикләрен һәм яр буе саклык полосалары чикләрен билгеләү кагыйдәләре, Россия Федерациясе Су кодексының 65 статьясы, «Күчемсез мөлкәтне дәүләт теркәвенә алу турында» 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы федераль законның 32 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы мәсьәләләре» 2005 елның 6 июлендәге 325 номерлы карары нигезендә һәм башкарылган эшләр нәтиҗәсендә су объектларының су саклау зоналары чикләре һәм яр буе саклык полосалары чикләре турындагы белешмәләрне дәүләт су реестрына һәм Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына кертү максатында **боерык бирәм**:

1. Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларының су саклау зоналары һәм яр буе саклык полосалары киңлеген Россия Федерациясе Су кодексының 65 статьясы нигезендә әлеге чикләрдә хуҗалык һәм башка төр эшчәнлекне гамәлгә ашыруның махсус режимын исәпкә алып билгеләргә:

1.1. Кече Чирмешән елгасы:

су саклау зонасының киңлеге – 200 м;

яр буе саклык полосасының киңлеге: ярның авышлыгы 3 һәм аннан күбрәк градуска тигез булганда – 50 м, ярның авышлыгы 3 градустан кимрәк булганда – 40 м, капма-каршы яисә нульле авышлык булганда – 30 м.

1.2. Казансу елгасы:
су саклау зонасының киңлеге – 200 м;
яр буе саклык полосасының киңлеге – 200 м.

1.3. Кәминкә елгасы:
су саклау зонасының киңлеге – 50 м;
яр буе саклык полосасының киңлеге – 50 м.

2. Су объектларын саклау бүлегенә (В.А.Долгов):

2.1. Материалларны билгеләнгән тәртиптә дәүләт су реестрына кертү өчен Су ресурсларының федераль агентлыгына җибәрергә.

2.2. Белешмәләрне билгеләнгән тәртиптә Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына кертү өчен Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә материалларны җибәрергә.

2.3. Белешмәләрне су саклау зоналары һәм яр буе саклык полосалары чикләре үз территорияләренә карата билгеләнә торган муниципаль районнарның җирле үзидарә органнарына җибәрергә.

3. Экологик куркынычсызлыкны тәэмин итү өлкәсендәге проектларны пропагандалау бүлегенә (Е.В.Веселова) әлеге боерыкны татар теленә тәрҗемә итәргә.

4. Хокукый тәэминат бүлегенә (А.И.Ткачук) әлеге боерыкны теркәү өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

5. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары О.В.Манидичевка йөкләргә.

Министр вазыйфаларын башкаручы А.М.Шиһапов